ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.08.2019 г. Заинск №428

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 27 августындагы 1397 номерлы «Зәй муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» карары белән расланган Зәй муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 21 июнендәге 505 нче номерлы « Дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары һәм аерым типка карамаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 августындагы 665 нче номерлы «Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча Министрлыкка буйсынучы ведомстволарга караган оешмалар, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 27 августындагы 1397 номерлы «Зәй муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты ведомство буйсынуындагы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

V бүлегендә:
2.4 пунктының алтынчы абзацында «26,5» санын «41,0» санына алмаштырырга;
6 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 нчы таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмәләр күләме

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | 41,0 |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче | 41,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче- дүртенче | 41,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче | 46,0 |
| | икенче | 49,0»; |

4.4 пунктның алтынчы абзацында «26,5» санын «41,0» санына алмаштырырга;
11 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 нче таблица

Размеры надбавок за интенсивность труда

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалары | 41,0 |
| «Урта буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | аккомпаниатор, костюм мөдире | 49,0 |
| | түгәрәк җитәкчесе, һәвәскәр берләшмә, мәнфәгатьләр клубы җитәкчесе, культорганизатор | 61,0 |
| «Әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфасы» һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалары | 49,0 |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалары | 49,0 |

VIII бүлектәге 8 пунктның бишенче абзацында «10» санын «20» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Л.Г.Федотова
7-52-84